**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«26» октябрь 2022 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогы гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Красномайский поселогы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, аларның толл калган хатыннарыннан, 1 төркем инвалидларыннан тыш 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- МТЗ-82.1 тракторы һәм аңа тагылмалы җиһазлар сатып алуга;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлегенең Красномайский торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау һәм таш түшәү.

Халык җыенында рәислек итүче: В.И. Гаврилов

Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов